**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Бигеш авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**№ 139 17.09.2018**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында**

Зәй муниципаль районы Бигешавыл җирлегенең гамәлдәге Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, "Җирле үзидарә органнарын оештыруны камилләштерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»2018 елның 18 апрелендәге 83-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алу өчен Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.
3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигешавыл җирлеге Уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алганнан соң билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.
4. Карар билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алынганнан һәм басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
5. Әлеге карарга кушымтаның 1 пунктындагы «б» пунктчасы, 13 пунктның «а» пунктчасы 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
6. Карар үтәлешенә контрольне үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **И.Р.Вәлиев.**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Бигешавыл җирлеге Советының 2018 елның 17 .09. 139 номерлы
карарына кушымта.

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Бигеш авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр**

Зәй муниципаль районы Бигешавыл җирлеге Уставына түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр кертергә:

1. 5 статьяның 1 өлешендә:

а) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, әлеге кагыйдәләргә туры китереп, җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;»;

б)14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14) каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым туплану) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу;»;

2. 6 статьяның 11 пункты үз көчен югалткан дип танырга;
3. 10 статьяның 7 пунктына «, иҗтимагый фикер алышулар»сүзләрен өстәргә;
4. Түбәндәге эчтәлекле 18.1 статьяны өстәргә:

«18.1 статья. Авыл торак пункты старостасы

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл иткәндә җирле үзидарә органнарының һәм авыл торак пунктында яшәүчеләрнең үзара хезмәттәшлеген оештыру өчен авыл җирлегендә яки авылара территориядә урнашкан торак пунктта авыл торак пунктының старостасы билгеләнергә мөмкин.

2. Авыл торак пункты старостасы составына әлеге авыл торак пункты кергән җирлек Советы тарафыннан авыл торак пункты территориясендә яшәүче һәм актив сайлау хокукына ия затлар арасыннан авыл торак пункты гражданнары җыены тәкъдиме буенча билгеләнә.

3. Авыл торак пункты старостасы дәүләт вазыйфасын, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын, муниципаль вазыйфаны яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче зат була алмый, хезмәт мөнәсәбәтләрендә һәм җирле үзидарә органнары белән турыдан-туры бәйле башка мөнәсәбәтләрдә тора алмый.

4. Түбәндәге затлар авыл торак пункты старостасы була алмый:

1) дәүләт вазыйфасын, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын, муниципаль вазыйфаны яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче;

2) суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылган затлар;

3) суд хөкеме тулысынча үтәп бетерелмәгән яисә хөкем ителгәнлеге алынмаган затлар.

5. Авыл торак пункты старостасының вәкаләтләр срогы - биш ел.

Авыл торак пункты стростасының вәкаләтләре әлеге авыл торак пункты кергән авыл җирлеге Советы карары белән, гражданнар җыены тәкъдиме буенча, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ Федераль законның 40 статьясы 10 өлешенең 1-7 пунктларында билгеләнгән очракларда вакытыннан алда туктатыла.

5. Авыл торак пункты старостасыаңа йөкләнгән бурычларны хәл итү өчен:

1) авыл торак пунктында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр һәм башка оешмалар белән хезмәттәшлек итә;

2) халык белән, шул исәптән җыеннарда, җыелышларда, конференцияләрдә катнашу юлы

белән, хезмәттәшлек итә, мондый чаралар нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгатьләр һәм тәкъдимнәр җибәрә, шул исәптән, җирле үзидарә органнары тарафыннан мәҗбүри каралырга тиешле муниципаль хокукый актлар проектлары рәвешендә.
3) авыл торак пунктында яшәүчеләргә җирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирә, шулай ук аларга җирле үзидарә органнарыннан алынган башка мәгълүматны җиткерүдә ярдәм итә;
4) җирле үзидарә органнарына ачык тыңлауларны һәм җәмәгать фикер алышуларын оештыруда һәм уздыруда, аларның нәтиҗәләрен авыл торак пунктында яшәче халыкка җиткерүдә ярдәм итә;
5) муниципаль берәмлек уставында һәм (яисә) җирлек Советының норматив хокукый актында Татарстан Республикасы законы нигезендә каралган башка вәкаләтләрне һәм хокукларны гамәлгә ашыра.»;
5. 19 статьяда:
а) статьяның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«19 статья. Ачык тыңлаулар, җәмәгать фикер алышулары»;
б) 19 статьяның 3 өлеше 3 пункты үз көчен югалткан дип танырга;
в) түбәндәге эчтәлекле 11 өлешне өстәргә:
«11. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне межалау проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар, җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү турында карарлар проектлары, капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, үзгәртеп коруның чик параметрларыннан читләшүгә рөхсәт бирү, җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен үзгәртү мәсьәләләре буенча карар проектлары буенча, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре булмаганда, җәмәгать фикер алышулары яисә ачык тыңлаулар үткәрелә, аларны оештыру һәм үткәрү тәртибе, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнар нигезләмәләрен исәпкә алып, җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.»;
6. 22статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«22 статья. Гражданнар җыены
1. Гражданнар җыены халык тарафыннан турыдан-туры җирле үзидарә гамәлгә ашырылу һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашуы рәвеше булып тора.
2. Гражданнар җыены «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда каралган очракларда һәм «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармашбаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турында»нигезләмә нигезендә үткәрелә.
3. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясында каралгандатүбәндәге очракларда гражданнар җыены үткәрелергә мөмкин:
1) күрсәтелгән торак пункт территориясен башка җирлек (муниципаль район)территориясенә кертүгә китергән әлеге торак пункт составына кергән җирлек (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча;
2) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә әлеге җирлекнең чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча;
3) әгәр сайлау хокукына ия җирлектә яшәүчеләрнең саны 100 дән артык кеше булса,муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләрен гражданнар җыены гамәлгә ашыра торган җирлектәҗирлекнең вәкиллекле органын төзү,аның саны һәм вәкаләтләр срогы мәсьәләсе турында;
4) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан башкарыла торган җирлектә, гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча;
5) шәһәр эчендәге район составына керүче җирлек,федераль әһәмияттәге шәһәрнең шәһәр эчендәге территориясе, шәһәр округы яисәяисә муниципаль район чикләрендәге авылара территориядә урнашкан торак пункттаәлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

6) авылара территориядә урнашкан торак пунктта җирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләр буенча халык инициативасын тәкъдим итү максатларында;
7) әгәр авыл җирлегендә халык саны 100 кешедән артмаса, авыл халкы тыгызлыгы түбән булган яисә үзәктән читтә урнашкан, барып җитү мөмкин булмаган җирлектә җирлекне бетерү мәсьәләсе буенча;
8) авыл торак пунктында авыл торак пунктының старостасы кандидатурасын күрсәтү мәсьәләсе буенча, шулай ук авыл торак пункты старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча;
9) авыл торак пунктында гражданнар җыены шулай ук муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе составына кандидатуралар күрсәтү максатларында үткәрелергә мөмкин.
4. Гражданнарның җыены муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан яисә сайлау хокукына ия, кимендә 10 кешедән торган торак пунктта яшәүчеләр төркеме инициативасы белән чакырылырга мөмкин.
5. Җыенны уздыру инициативасын хуплап җыелырга тиешле имзалар саны сайлау хокукына ия гражданнар, даими яисә башлыча яшәүче, торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнарның 5 процентын тәшкил итә, әмма 25 имзадан да ким була алмый.
6. Муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан чакырыла торган гражданнар җыены муниципаль берәмлек башлыгы карары, инициатив төркем тарафыннан чакырыла торган гражданнар җыены муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән билгеләнә.
7. Торак пунктта яшәүчеләргә алдан ук гражданнар җыенын уздыру вакыты һәм урыны турында хәбәр ителә, «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигешавыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыенын уздыру тәртибе турында» нигезләмәдә билгеләнгән тәртипкә туры китереп, гражданнар җыенын хәл итүгә чыгарыла торган мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый акт проекты һәм материаллар белән алдан ук таныштырыла.
8. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокукый актлар булып тора, муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш.»
7. 29 статьяда:
а) түбәндәге эчтәлекле 7 өлеш өстәргә:
«7. Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затының коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләренең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) карары буенча үткәрелә.»;
б) түбәндәге эчтәлекле 8 өлешне өстәргә:
«8. Әлеге статьяның 7 өлеше нигезендә уздырылган тикшерү нәтиҗәсендә «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 03 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәү фактлары ачыкланганда, Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) депутатның, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән тиешле карарны кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына яисә судка мөрәҗәгать итә.»;

в) түбәндәге эчтәлекле 9 өлешне өстәргә:

«9. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр җирле үзидарә органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм (яисә) массакүләм мәгълүмат чараларына муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгару өчен бирелә.»;

г) түбәндәге эчтәлекле 10 өлешне өстәргә:

«10. Җирлек Советы депутаты, җирле үзидарәнең даими нигездә вәкаләтләр башкаручы сайланулы вазыйфаи заты граждан, административ яисә җинаять эше буенча йә административ хокук бозу турындагы эш буенча яклаучы яисә вәкил (законлы вәкиллек очракларыннан тыш) сыйфатында катнаша алмый.»;

8. 32 статьяга түбәндәге эчтәлекле 30 пунктны өстәргә:

«30) муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау;»;

9. 39 статьяга түбәндәге эчтәлекле 7 өлешне өстәргә:

«7. Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) җирлек Советы депутатының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату өчен нигез булып, әлеге гариза җирлек Советына кергән көн тора.»;

10. 42 статьяда:

а) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Җирлек башлыгы «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 03 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиеш.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 7 өлешне өстәргә:

«7. Җирлек башлыгына ярамый:

1) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы идарәсендә яисә коммерциягә карамаган оешма идарәсендә, федераль законнарда каралган очраклардан тыш, (Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләр советы идарәсендә, башка муниципаль берәмлекләр берләшмәләрендә, сәяси партиядә, съездда (конференцияләрдә) яки башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашудан тыш)һәм оешма идарәсендә катнашу җирле үзидарә органы исеменнән Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырылган очраклардан тыш, катнашырга;
2) укыту, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса;
3) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яки күзәтчелек советлары, Россия Федерациясе территориясендә эшләүче чит ил коммерцияле булмаган хөкүмәтнеке булмаган оешмалары һәм аларның структур бүлекчәләре составына керергә.»;

11. 43.1 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирлек башлыгы урынбасары җирлек Советы регламентында билгеләнгән вазыйфалар бүленеше буенча функцияләрне башкара, җирлек башлыгы кушкан йөкләмәләрне үти, ул вакытлыча (авыру яисә отпускта булу) булмаганда, үз бурычларын үти алмаганда, вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылганда, суд карары белән сак астына алынганда яисә вазыйфасыннан вакытлыча читләштерү рәвешендә процессуаль мәҗбүр итү чаралары

кулланылганда җирлек башлыгы вазыйфаларын башкара.»;
12. 44 статьяда:
а) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3. Җирлек башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, җирлек Советы тарафыннан үз составыннан сайлана торган җирлек башлыгын сайлау вәкаләтләр туктатылган көннән алып алты айдан да соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.»;
б) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4. Әгәр җирлек Советының вәкаләтләр чоры тәмамланганчы алты айдан кимрәк вакыт калган булса, җирлек башлыгын җирлек Советы составыннан сайлау җирлек Советының яңа сайланган беренче утырышында гамәлгә ашырыла.»;
в) 4.1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4.1. Җирлек башлыгы, аның вәкаләтләре Татарстан Республикасы Президентының (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенең) җирлек башлыгы вазыйфасыннан читләштерү турындагы хокукый акты нигезендә вакытыннан алда туктатылган яисә җирлек башлыгы җирлек Советы карары нигезендә отставкага җибәрелгән очракта әлеге хокукый актка яисә карарга суд тәртибендә шикаять бирә, җирлек Советы, суд карары законлы көченә кергәнче, җирлек Советы үз составыннан сайланучы җирлек башлыгын сайлау турында карар кабул итәргә хокуклы түгел.»;
13. 47 статьяның 6 пунктында:
а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«- каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнаша;»;
б) өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«- җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләренең үтәлешен тикшереп тора, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыра;»;
14. 69 статьяның 3 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:
«Җирле үзидарә органнары арасында төзелгән муниципаль хокукый актны яисә килешүне рәсми бастырып чыгару тиешле муниципаль берәмлектә тарала торган вакытлы матбугат басмасында тулы текстның беренче басмасы санала.

Муниципаль хокукый актларны һәм килешүләрне рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен җирле үзидарә органнары шулай ук челтәр басмасыннан файдаланырга хокуклы. Муниципаль хокукый актның тулы тексты рәсми челтәр басмасында басылып чыккан (урнаштырылган) очракта күләмле график һәм таблицалы кушымталар басмада китерелмәскә мөмкин.»;
15. 79 статьяда:
а) 1 өлештә «җирлек» сүзләреннән соң «(җирлек составына керә торган торак пункт)» сүзләрен өстәргә;
б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән гражданнарның бер тапкыр бирелә торган түләүләрен кертү һәм алардан файдалану мәсьәләләре җирле референдумда, ә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы 1 өлешенең 4.1 пунктында каралган очракларда, гражданнар җыенында хәл ителә.